**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Кукеевского**
**сельского поселения**
**Рыбно Слободского**
**муниципального района**

**Новая ул., дом 5,**
**с.Кукеево, 422669**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе**
**муниципаль районы**
**Куки**
**авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

**Яна урамы, 5 нче йорт,**
**Куки авылы , 422669**

**Тел.: (84361) 30581 факс: (84361)30581, эл.адрес: Kuk.Rs@tatar.ru**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2022 Күки авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм “Җирләү һәм мәет кую эше турында” 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законын, “Татарстан Республикасында җирләү һәм мәет кую эше турында” Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарын үтәү йөзеннән, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымтада күрсәтелгәнчә 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм 2022 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт, адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык-Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2022 елның 1 номерлы карарына кушымта

**2022 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2646,95 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегендә ире (хатыны), якын туганнары, бүтән туганнары яисә мәрхүмнең законлы вәкиле булмаганда яки алар тарафыннан мәет куюны гамәлгә ашыру мөмкин булмаганда яисә җирләү бурычын үз өстенә ала торган башка зат булмаганда, мәет кую буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча түләүсез нигездә (бушлай) күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе (хакы)**

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетне кәфенләү | 500,00 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2146,95 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 997,28 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3320,45 |
| Җәмгысе: | 6964,68 |